**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«25» 04 2021 ел Яр Чаллы № 1238

**Ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган, тәрбиягә бала алган гаиләләрдә яшәүче, опекага (попечительлеккә) алынган яки ятим балалар һәм ата-ана каравынна мәрхүм калган балалар өчен оешмаларда яшәгән балалар милекчеләре булган торак биналарның социаль наем шартнамәләре буенча яллаучылар яисә яллаучыларның гаилә әгъзалары тарафыннан кулланылышын һәм сакланышын, торак биналарның тиешле санитар һәм техник торышын, торак бина белән идарә итүне контрольдә тоту максатында тикшерүләр үткәрү буенча комиссия турында**

«Ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган, тәрбиягә бала алган гаиләләрдә яшәүче, опекага (попечительлеккә) алынган яки ятим балалар һәм ата-ана каравынна мәрхүм калган балалар өчен оешмаларда яшәгән балалар милекчеләре булган торак биналарның социаль наем шартнамәләре буенча яллаучылар яисә яллаучыларның гаилә әгъзалары тарафыннан кулланылышын һәм сакланышын, торак биналарның тиешле санитар һәм техник торышын, торак бина белән идарә итүне контрольне гамәлгә ашыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 30 апрелендәге 374 номерлы карарын үтәү йөзеннән

**КАРАР БИРӘ:**

1. Ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган, тәрбиягә бала алган гаиләләрдә яшәүче, опекага (попечительлеккә) алынган яки ятим балалар һәм ата-ана каравынна мәрхүм калган балалар өчен оешмаларда яшәгән балалар милекчеләре булган торак биналарның социаль наем шартнамәләре буенча яллаучылар яисә яллаучыларның гаилә әгъзалары тарафыннан кулланылышын һәм сакланышын, торак биналарның тиешле санитар һәм техник торышын, торак бина белән идарә итүне контрольдә тоту максатында тикшерүләр үткәрү буенча комиссия (алга таба – комиссия) төзергә һәм 1 кушымта нигезендә составын расларга.

2. 2 кушымта нигезендә комиссия турында нигезләмәне расларга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый

мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында (http://tukay.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ * ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТУКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА * ИНН 1639031830

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның ___ апрелендәге ___ номерлы карарына 1 кушымта

Ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган, тәрбиягә бала алган гаиләләрдә яшәүче, опекага (попечительлеккә) алынган яки ятим балалар һәм ата-ана каравынна мәрхүм калган балалар өчен оешмаларда яшәгән балалар милекчеләре булган торак биналарның социаль наем шартнамәләре буенча яллаучылар яисә яллаучыларның гаилә әгъзалары тарафыннан кулланылышын һәм сакланышын, торак биналарның тиешле санитар һәм техник торышын, торак бина белән идарә итүне контрольдә тоту максатында тикшерүләр үткәрү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Бариев<br>Илфак Шамил улы | Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| Дозорова<br>Валентина Борисовна | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы мөдире, комиссия секретаре |
| Эшче төркем әгъзалары: | |
| Мозафарова<br>Светлана Зөфәр кызы | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторының әйдәп баручы белгече |
| Саетгәрәев<br>Фәнис Мизхәт улы | «Тукай муниципаль районының капиталь төзелеш хезмәте» МУП директоры |

тикшерү үткәрелә торган торак урын урнашкан җирлекнең башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча);

тикшерү үткәрелә торган торак урын урнашкан күпфатирлы йорт белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма вәкиле (килешү буенча).

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның ___ апрелендәге ___ номерлы карарына 2 кушымта

Ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган, тәрбиягә бала алган гаиләләрдә яшәүче, опекага (попечительлеккә) алынган яки ятим балалар һәм ата-ана каравынна мәрхүм калган балалар өчен оешмаларда яшәгән балалар милекчеләре булган торак биналарның социаль наем шартнамәләре буенча яллаучылар яисә яллаучыларның гаилә әгъзалары тарафыннан кулланылышын һәм сакланышын, торак биналарның тиешле санитар һәм техник торышын, торак бина белән идарә итүне контрольдә тоту максатында тикшерүләр үткәрү буенча комиссия турында нигезләмә

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган, тәрбиягә бала алган гаиләләрдә яшәүче, опекага (попечительлеккә) алынган яки ятим балалар һәм ата-ана каравынна мәрхүм калган балалар өчен оешмаларда яшәгән балалар милекчеләре булган торак биналарның социаль наем шартнамәләре буенча яллаучылар яисә яллаучыларның гаилә әгъзалары тарафыннан кулланылышын һәм сакланышын, торак биналарның тиешле санитар һәм техник торышын, торак бина белән идарә итүне контрольдә тоту максатында тикшерүләр үткәрү буенча комиссия (алга таба – комиссия), ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган, тәрбиягә бала алган гаиләләрдә яшәүче, опекага (попечительлеккә) алынган яки ятим балалар һәм ата-ана каравынна мәрхүм калган балалар өчен оешмаларда яшәгән балалар милекчеләре булган торак биналарның социаль наем шартнамәләре буенча яллаучылар яисә яллаучыларның гаилә әгъзалары тарафыннан кулланылышын һәм сакланышын, торак биналарның тиешле санитар һәм техник торышын, торак бина белән идарә итүне тикшерү өчен (алга таба – торак биналар, ятим балалар), Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) төзегән даими эшләүче коллегиаль орган булып тора.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясенең норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына, әлеге нигезләмәгә таяна.

II. Комиссия вәкаләтләре

2.1. Комиссия вәкаләтләренә законнар нигезендә Башкарма комитет (аның структур бүлекчәсе) тарафыннан опека һәм попечительлек органы вәкаләтләре гамәлгә ашырылган ятим балаларның торак биналарыннан файдалануны һәм аларны саклауны тикшереп тору максатында, торак биналарның тиешле санитар һәм техник торышын, торак бина белән идарә итүне контрольдә тоту максатында

башкарыла торган планлы һәм планнан тыш тикшерүләр керә (алга таба – тикшерүләр).

2.2. Тикшерүләр үткәрүнең тәртибе, нигезләре, вакыты һәм сроклары Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

2.3. Тикшерүләр барышында комиссия Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган чараларны гамәлгә ашыра (гамәлгә ашыруны тәэмин итә).

2.4. Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча торак бинаның сакланышын тикшерү акты төзелә (алга таба – тикшерү акты), ул тикшерү үткәрүдә катнашкан комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

Тикшерү актын рәсмиләштерүгә карата таләпләр Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

## III. Комиссиянең эш тәртибе

3.1. Комиссия составына рәис, секретарь һәм комиссия әгъзалары керә.

3.2. Комиссия утырышлары чираттагы елга расланган планлы тикшерүләр планын үтәү йөзеннән, шулай ук Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигезләр булганда үткәрелә.

3.3. Комиссия рәисе, ә ул вакытлыча булмаганда – комиссия секретаре:

3.3.1. Комиссия утырышының көн тәртибен билгели;

3.3.2. Комиссия утырышларын үткәргәндә һәм тикшерүләр үткәргәндә җитәкчелек итә;

3.3.3. Тикшерү актын раслый.

3.4. Комиссия секретаре:

3.4.1. Утырыш һәм тикшерүләр үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында комиссия әгъзаларына хәбәр итә;

3.4.2. Тикшерү үткәрү турында хокукый акт әзерләүне тәэмин итә. Күрсәтелгән актка карата таләпләр Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә;

3.4.3. Тикшерү үткәрү турында хәбәрнамә әзерләүне һәм әлеге хәбәрнамәне ятим балалар адресына җибәрүне тәэмин итә. Күрсәтелгән хәбәрнамәгә таләпләр Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә;

3.4.4. Тикшерү актын рәсмиләштерүне тәэмин итә.

3.5. Әлеге нигезләмәнең 3.4 пункты 3.4.1 пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә түбәндәге ысулларның берсе белән җибәрелергә тиеш:

- телефон буенча (шул исәптән мобиль телефонга) хәбәр итү;
- электрон почта адресына;
- факсимиль элемтә аша;
- мобиль телефон аша кыска текст хәбәрләр (СМС-хәбәрләр) тапшыру;
- мессенджерлар аша хәбәрләр тапшыру;
- хәбәрнамәне теркәүне тәэмин итә торган башка чаралардан файдалану.

3.6. Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының билгеләнгән санынннан яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы була.

3.7. Комиссия әгъзасы тарафыннан үз тавышын кемгә дә булса, шул исәптән комиссиянең башка әгъзасына тапшыру рөхсәт ителми.

3.8. Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән комиссия утырышында катнашучы комиссия әгъзалары санынннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булганда комиссия рәисе (комиссия рәисе булмаган очракта комиссия секретаре) хәлиткеч тавышка ия.